*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2021-2022 нче уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 52**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Басымы дөрес күрсәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *бар-ды-гыз-мы'*;
   **ә) *бар-ды-гы'з-мы*;**
   б) *бар-ды'-гыз-мы*;
   в) *ба'р-ды-гыз-мы*.

2. Неологизмны билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) *лифтинг*;**
   ә) *чирү*;
   б) *ошбу*;
   в) *арыш*.

3. Рәвеш ясагыч кушымчаларны билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) -ча/-чә, -лап/-ләп;**
   ә) -чы/-че, -даш/-дәш;
   б) -ла/-лә, -лаш/-ләш;
   в) -лы/-ле, -чан/-чән.

4. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   *Бер ялган **сөйләсәң**, тугыз дөрес сүзеңә дә ышанмаслар.* (Мәкаль)
   а) хикәя фигыль;
   ә) рәвеш;
   б) сыйфат фигыль;
   **в) шарт фигыль.**

5. Кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *белән;*
   **ә) *иң;***
   б) *юк;*
   в) *уф.*

6. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Озын сүздән кыска җеп яхшы.* (Мәкаль)

а) *озын*;

ә) *сүздән*;

**б) *җеп*;**

в) *яхшы*.

7. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Озынның бөгеләсе килми, кысканың үреләсе килми.* (Мәкаль)

а) гади җөмлә;

**ә) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә;**

б) теркәгечле тезмә кушма җөмлә;

в) иярченле кушма җөмлә.

8. Җөмләдәге иярчен компонентның мәгънә ягыннан төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Сиңа каты сүз әйтсәләр дә, йомшак сүз белән җавап бир.* (Мәкаль)

**а) иярчен кире шарт җөмлә;**

ә) иярчен шарт җөмлә;

б) иярчен вакыт җөмлә;

в) иярчен тәмамлык җөмлә.

## II. Теоретик бирем.

Күпнокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(8 балл)**

*[м], [**н**], [ң] – борын тартыклары. Кулланылыштан төшеп калган сүзләрне **искергән** сүзләр дип атыйлар. Сүзнең тамырына яки нигезенә **ясагыч** кушымча ялганып, яңа сүз ясала. Соң, тыш, башка – **чыгыш** килешен таләп итүче бәйлекләр. Фигыльләр барлыкта һәм **юклыкта** кулланыла. **Тиңдәш** һәм тиңдәш түгел аергычлар була. Аныклагыч ияреп килгән кисәк **аныкланмыш** була. Иярчен **урын** җөмлә баш җөмләнең урын хәле урынында килә.*

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итегез. **(16 балл)**

*Юра и Толя шли неподалеку от берега реки.*

- *Интересно, - сказал Толя, - как это совершаются подвиги? Я все время мечтаю о подвиге!*

- *А я об этом даже не думаю, - ответил Юра и вдруг остановился...*

*С реки донеслись отчаянные крики о помощи. Оба мальчика помчались на зов. Юра на ходу сбросил туфли, отшвырнул в сторону книги и бросился в воду. А Толя бегал по берегу и кричал:*

- *Кто звал? Кто кричал? Кто тонет?*

*Между тем Юра с трудом втащил на берег плачущего малыша.*

- *Вот кто кричал? – обрадовался Толя. – Живой? Ну и хорошо! А ведь не подоспей мы вовремя, кто знает, что было бы!*

(Валентина Овсеева)

2. Сезнең өчен батырлык нәрсә ул? Батырлык эшләү өчен кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Нинди батырлыклар турында ишеткәнегез бар? Шул хакта фикерләрегезне 12 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**